**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2024 елның «22» мартыннан | № 115

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2014 елның 17 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2014 елның 17 гыйнварындагы 16 номерлы карарына (2018 елның 22 мартындагы 129 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм түләтү тәртибендә:

2 бүлектәге 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм  Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм түләтү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 гыйнварындагы 16 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында» 2018 елның 22 мартындагы 129 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип таныйрга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов